БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_27_» __09__ 2019 ел № _306_

**Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2013 елның 12 августындагы 174 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының гражданлык хәле актларын теркәү бүлегендә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең һава киңлеген кулллануның Федераль кагыйдәләрен раслау турында» РФ Хөкүмәтенең 2010 елның 11 мартындагы 138 номерлы Карары (2018 елның 13 июнендәге редакциядә) нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының Гражданлык хәле актларын теркәү бүлегендә үз-үзеңне тоту кагыйдәләренең 5 нче пунктына түбәндәге эчтәлектәге җөмләне өстәп, үзгәрешләр кертергә:

« - 50 м дан артык биеклектә салютлар һәм фейерверклар уздырганда һава киңлеген файдалануга Бердәм система үзәкләреннән рөхсәт алуны раслаучы документларның күчермәләре.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов